ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

# Татар халык Мәкальләре



# ТУЛПАР, ТОЯГЫ КЫЗСА, КАНАТЛАНЫП ОЧАР

*Эштә җитез, уңган, үзен аяп тормый, күп хезмәт итә, кызып китеп, тиз эшли торган кеше турында әйтелә.*





# ЮЛГА ЧЫКСАҢ, АЛДАГЫ КЕШЕНЕ ҖИТӘРГӘ ТЫРЫШ, АРТТАГЫСЫН КӨТМӘ

*Берәр эшне башлап, максатка тизрәк ирешер өчен, эленке-салынкы булмыйча, җәһәт эш итәргә кирәклеген аңлата.*

# ҖИККӘН АТЫҢ ҖИЛДӘЙ БУЛСЫН

*Тормышта, җитди эшләр башкарганда, җебегән, ялкау кешеләргә таянма, ярдәмчеләрең зирәк, үткен булсын дигәнне аңлатып әйтелә.*





*Төрле кыен хәлләргә дә чыдап,
җиңеп чыккан кеше турында әйтелә.*

# АТ – ТАУДА, ЕГЕТ ЯУДА СЫНАЛА



# САБЫР ИТКӘН – МОРАДЫНА ҖИТКӘН

*Эшне кыен дип ташламыйча, чыдам булып һәм ихтыяр көчен туплап, уңай нәтиҗәгә ирешкән кеше турында әйтелә.*

# САБЫР ЧЫДЫЙ, САБЫРСЫЗ ЕЛЫЙ



*Авырлыклардан курыкмыйча, алда торган эшне азагынача башкарып чыккан кеше турында әйтелә.*

# АБРУЙ — ИРНЕҢ КУӘТЕ



*Рухы белән көчле, кешеләргә ярдәмчел, коллективта хөрмәт, абруй казанган кешегә карата әйтелә.*

# ТӘРӘЗӘСЕНӘ КАРАМА, ДӘРӘҖӘСЕНӘ КАРА



*Кешене байлыгына, затлы йортына карап түгел, ә кешелеклелек сыйфатларына карап хөрмәт итәргә кирәк дигәнне аңлата.*

# КҮЛНЕҢ КҮРКЕ – КАМЫШ, ИРНЕҢ КҮРКЕ – НАМУС



*Ир-ат намуслы, уңай, матур сыйфатларга ия булырга тиеш дигәнне аңлата.*

# КИТАП — БЕЛЕМ ЧИШМӘСЕ

*Кеше белмәгәнен китаптан укып*
*белә ала, чөнки анда*
*кешелек дөньясы ачкан белемнәр*
*тупланган дигәнне аңлата.*




# ЭЗЛӘГӘН ТАБАР

*Тик тормаган, кызыксынган, хәрәкәттәге кеше, һичшиксез, ниндидер уңышка ирешә дигәнне аңлата.*



# ГЫЙЛЕМЛЕК – НУР, НАДАНЛЫК – ХУР

*Кеше надан булмаска, белемгә омтылырга, кызыксынып яшәргә тиеш дигәнне аңлата.*





# БУЛАСЫНЫҢ БУЫНЫННАН БИЛГЕЛЕ

*Баланың яшьтән үк гамәленә, эшенә, сүзенә, үзен тотышына карап, киләчәктә нинди кеше булып җитешәсен чамалап була дигәнне аңлата.*

# БУЛЫР АШЛЫК ШЫТЫМЫННАН БИЛГЕЛЕ

*Чәчкән игеннең ничек шытып чыгуына карап, көзен җыеп аласы уңышны чамалап була дигәнне аңлата.*





# БАЛАНЫҢ БАРМАГЫ АВЫРТЫР, АНАНЫҢ ЙӨРӘГЕ АВЫРТЫР

*Баласына килгән кыенлыкларны, авыру һәм уңышсызлыкларны ананың, үз йөрәгенә якын алып, үзенә төшкән авырлык кебек кабул итүен аңлатып әйтелә.*

# АТАНЫ КҮРЕП УЛ ҮСӘР, АНАНЫ КҮРЕП КЫЗ ҮСӘР



*Ата кеше үзе белгән һөнәрләргә, гореф-гадәтләргә – улын, ана кеше кызын өйрәтергә тиеш дигәнне аңлата.*

# АТА УЧАГЫН СҮНДЕРМӘ

*Ата йортын, туган нигезне онытма, олыгайган ата-анаңа һәрвакыт ярдәм итеп яшә дигәнне аңлатканда әйтелә.*



# АЛТЫ КӨН АЧ БУЛСАҢ ДА, АТА ГАДӘТЕН ҖУЙМА

*Нинди генә кыен хәлләргә очрасаң да, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне ташлама дигәнне аңлата.*



# ОСТАЛЫК — ИҢ ЗУР БАЙЛЫК



*Кулы һөнәр белгән оста һәрвакыт матур тормышка ирешә ала дигәнне искәртеп әйтелә.*



# УҢГАН ЕГЕТ ХУР БУЛМЫЙ

*Уңган-булган кеше беркайчан да югалып калмый, теләсә нинди эшне башкарып чыга ала дигәнне аңлата.*



# ОСТАНЫҢ КУЛЫ БИИ

*Эшне җиңел, тиз һәм ипле итеп башкарган оста куллы кешегә карата әйтелә.*




# БЕРДӘМЛЕК БАРДА – ТЕРЕКЛЕК БАР

*Бердәм, бер йодрыкка тупланып яшәгән җәмгыятькә яки, бер фикердә булып, тату яшәгән гаиләгә бернинди куркыныч та янамый, тыныч, матур тормыш алып барырга мөмкин дигәнне аңлата.*

# БЕРҮЗЕҢ ТАУ КҮЧЕРӘ АЛМЫЙСЫҢ

*Зур эшләрне ялгызың гына түгел, бергәләп башкарырга кирәклекне аңлата.*



# АЕРЫЛГАННЫ АЮ АШАР, БҮЛЕНГӘННЕ БҮРЕ АШАР



*Күмәк эшне башкарганда, коллективтан читләшеп, мәсьәләне һәркем үзенчә хәл итәргә тырышу уңай нәтиҗә бирмәскә мөмкин дигәнне аңлатып әйтелә.*



# ТЫРЫШКАН ТАБАР, ТАШКА КАДАК КАГАР

*Теләсә нинди кыенлыкларны да җиңеп, максатына ирешкән кешегә карата әйтелә.*



# ТЫРЫШКАННЫ ТАШ БӘЙЛӘ ДӘ БАТЫР, УЛ БАРЫБЕР КАЛКЫР

*Тырыш кеше, бернинди дә кыенлыкларга карамыйча, килеп чыккан каршылыкларны җиңеп, бирешмичә, максатына туры бара дигәнне аңлата.*

*Эшендә төрле кыенлыклар, уңышсызлыклар очраса да, куйган максатына ирешми калмый торган кешегә карата әйтелә.*




## ТЫРЫШ АСТА КАЛМАС, АСТА КАЛСА ДА, БЕР ӨСКӘ ЧЫГАР



# СУ ТҮБӘНГӘ ОМТЫЛЫР, КЕШЕ — ЮГАРЫГА

*Кешенең һәрвакыт алдына максат куеп, планнар корып яшәвен, аның табигате шундый булуын аңлатып әйтелә.*



# ОМТЫЛГАН ИРЕШЕР, ОМТЫЛМАГАН ЧӘРЕШЕР

*Куйган максатка ирешер өчен көч куярга, нык эшләргә кирәк, тырышмаган кеше уңышка ирешә алмый дигәнне аңлата.*



# АККАН СУ ЮЛЫН ТАБАР

*Тырышкан кеше һәрвакыт алдында торган максатына ирешүнең берәр юлын, әмәлен табар дигәнне аңлата.*

ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

ТОИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
www.tatbook.ru

# ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ

www.варислар.рф

«Татарстан Варислары» сериясенең электрон китаплары **www.варислар.рф** порталында урнаштырылган. Анда әлеге китапларны һәм аларга бәйле мультфильмнарны һәм мультимедиаларны йөкләтеп алу һәм карау мөмкинлеге дә бар.

Электронные книги серии «Татарстан Варислары» размещены на портале **www.варислар.рф** с возможностью скачивания и просмотра книг и соответствующих мультфильмов и мультимедиа.

© Татарское Детское Издательство
www.tdpress.ru

ISBN 978-5-6043753-3-4
9 785604 375334